**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы**
**«Уби авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең**
**Уби авылында гражданнар җыены**

# КАРАРЫ

**22.11.2024 ел.** **Уби авылы** **№ 1**

**2024 елның 22 ноябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Уби авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уби торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы нигезендә, Уби авыл җирлегенең 2019 елның 15 октябрендәге 60/1 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Уби авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә” нигезендә тавыш бирү йомгаклары турында хисап комиссиясе мәгълүматлары нигезендә 2024 елның 22 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде, аның нигезендә:

Тавыш бирү тәмамланган мизгелгә гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 265 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 159, бу торак пункт территориясендә гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә кертелгән гражданнар җыенында катнашучыларның 60,00 % ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 159 катнашучы тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучыларның 100% ын тәшкил итә;

"Каршы" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде, бу 0% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар чыгарылды:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Уби авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уби торак пунктында гражданнар җыенын 2024 елның 22 ноябрендә узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2025 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге Уби авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 850 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. 2025 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлеге Уби авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 850 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

4. Үзара салым акчаларын түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

2) инвалид балаларның ата-аналарын (уллыкка алучыларны, опекуннарны, попечительләрне), тулысынча дәүләт тәэминатында булган балалардан тыш;

3) махсус хәрби операциядә катнашучылар;

4) махсус хәрби операциядә катнашучыларның, шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булучыларның гаилә әгъзалары (хатыны, балигъ булган балалары, ата-аналары һәм хезмәткә сәләтсез башка иждивенецлар);

5) «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны;

6) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булганнарның гаилә әгъзалары (ире (хатыны), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм хезмәткә сәләтсез башка иждивеннар)

5. Әлеге карарны Уби авылы, Кызыл мәйдан урамы, 25 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендта бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уби авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Уби авыл җирлеге башлыгы
халык җыенында рәислек итүче: А.П. Ярухин